**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«ИСКЕ ДӨРЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«26» сентябрь 2017 ел № 15/4

Иске Дөреш авыл җирлегендә җирле
референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20,35 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 25 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясы, Иске Дөреш авыл җирлеге Советының 2017 елның 26 сентябрендәге 6/3 номерлы карары, Иске Дөреш авыл җирлеге Уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Иске Дөреш авыл җирлегендә 2016 елның 20 ноябренә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Иске Дөреш авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе белән берлектә Биклән авыл җирлегендә җирле референдумны уздыру турындагы инициативаны җирле референдум мәсьәләләре формулировкасы белән түбәндәге рәвештә чыгарырга::

Сез Биклән авыл җирлеге территориясендә 2016 елда Иске Дөреш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә бер тапкыр 100 (йөз) сум күләмендә түләү кертергә һәм Бөек Ватан сугышы инвалидлары, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнар һәм студентлар, көндезге формада белем алучы гражданнар һәм студентлар өчен бер тапкыр бирелә торган түләүне киметергә һәм әлеге категориядәге гражданнар өчен 50 сум (илле) күләмендә акча билгеләргә ризамы?

1) Авыл җирлеге чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне оештыру?

2) Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге юлларга карата юл эшчәнлеген тәэмин итү?

3) Ритуаль хезмәт күрсәтүне оештыруны тәэмин итү һәм җирләү урыннарын карап тоту?

3. Референдумны әзерләү һәм үткәрүне референдум комиссиясенә йөкләргә:

- муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе (Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының территориаль сайлау комиссиясе);

- Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлегенең участок сайлау комиссияләре.

4. Җирле референдум үткәрүгә бәйле чыгымнарны Иске Дөреш авыл җирлеге бюджеты хисабына башкарырга.

5. Әлеге карарны «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырырга.

6. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырып халыкка игълан итәргә.

7. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе И.Х. Бакиров